Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы

Ким авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 74-1 от 30 .10.2023

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ким авыл җирлеге Советының 2013 елның 28 июлендәге 43-1 номерлы карары белән расланган Спас муниципаль районы Ким авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (2016 елның 31 октябрендәге 16-1, 2018 елның 13 декбрендәге 50-3, 2019 елның 25 апрелендәге 57-1,2019 елның 12 сентябрендәге 66-2, 2020 елның 24 гыйнварындагы 82-1; 2020 елның 24 сентябрендәге 3-3, 2021 елның 06 апрелендәге 15-1, 2021 елның 07 маендагы 18-1; 2021 елның 04 июньдәге 21-1; 2022 елның 09 мартның 42-2; 2022 елның 15 июнендәге 48-1 номерлы; 2023 елның 20 февралендәге 62-2 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 04 августындагы 438-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 10 июлендәге 305-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә", ТР Спас муниципаль районы Ким авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ким авыл җирлеге Советының 2013 елның 28 июлендәге 43-1 номерлы карары белән расланган Спас муниципаль районы Ким авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (2016 елның 31 октябрендәге 16-1, 2018 елның 13 декбрендәге 50-3, 2019 елның 25 апрелендәге 57-1,2019 елның 12 сентябрендәге 66-2, 2020 елның 24 гыйнварындагы 82-1; 2020 елның 24 сентябрендәге 3-3, 2021 елның 06 апрелендәге 15-1, 2021 елның 07 маендагы 18-1; 2021 елның 04 июньдәге 21-1; 2022 елның 09 мартның 42-2; 2022 елның 15 июнендәге 48-1 номерлы; 2023 елның 20 февралендәге 62-2 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 36 статьяның 11 өлешендәге 3 абзацын үз көчләрен югалткан дип танырга.

1.2. 30 статьяның 2 пунктындагы 2 абзацына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

“Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрындагы территориаль планлаштыру документларында күрсәтелгән торак пунктларның чикләренең урнашу урыны турында (шул исәптән торак пунктларның чикләрен җир кишәрлекләре чикләре белән кисешкән очракта) мәгълүматларның туры килмәве, ул күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына торак пунктлар чикләре турында белешмәләр кертелгәндә федераль закон нигезендә үзгәртелгән күрсәтелгән торак пунктларның чикләре урынын тасвирлауга;”

" - территориаль зоналар чикләре турында белешмәләрне күчемсез мөлкәт Бердәм дәүләт реестрында күрсәтелгән территориаль зоналарның чикләре тасвирламасында булган территориаль зоналар чикләре турында белешмәләрнең туры килмәве, ул территориаль зоналар чикләре турында белешмәләр күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертелгәндә федераль закон нигезендә үзгәртелде.";

1.3. 32 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

" Территориаль зоналар чикләре муниципаль берәмлекләр, торак пунктлар, җир кишәрлекләре чикләрен кисеп үтә алмый (Россия Федерациясе Җир кодексында яисә башка федераль законда каралган очракларда чикләре территориаль зоналар чикләрен кисеп үтә ала торган җир кишәрлегеннән тыш). Территорияләрдән, мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләреннән, федераль әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләреннән, Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләре чикләреннән файдалануның махсус шартлары булган территориаль зоналар чикләре белән кисешү рөхсәт ителә.";

2. Әлеге карарның 1.2, 1.3 пункты 2024 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Ким авыл җирлеге башлыгы В.В. Синчугов